| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 14 “14” 01 2021 ел

«Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында алты һәм аннан күбрәк савым сыеры булган гражданнарга саву аппараты сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 7 мартындагы 151 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Монополиягә каршы законнарны бозуның 14.12.2020 һәм монополиягә каршы законнарны бозуның билгеләрен үз эченә алган гамәлләрне (гамәл кылмауларны) туктату турында кисәтүне карап, монополиягә каршы законнарны бозуны бетерү максатларында, ТР Спас муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында алты һәм аннан күбрәк савым сыеры булган гражданнарга саву аппараты сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 07 мартындагы 151 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы бюджетыннан шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм алты һәм аннан күбрәк савым сыеры булган гражданнарга саву аппаратын сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибендә:

а) 2.1 пунктының дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булмау турында белешмә субсидия алуга гариза белән мөрәҗәгать иткән айдан алдагы айның беренче числосына;».

б) 2.3 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«конкурс комиссиясе тарафыннан 7 баллдан да ким булмаган күләмдә бәяләнде».

1.1. 4.8 пунктының 2 һәм 3 юллары - Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында алты һәм аннан күбрәк савым сыеры булган гражданнарга саву аппаратын сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү буенча комиссия турында нигезләмәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2 | Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен файдаланыла торган җир кишәрлегенә хокук билгели торган документ (таныклык) яки күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә булу:<br>Хокук билгели торган документ булганда<br><br>Хокук билгели торган документ булмаганда | 1 - 5 балл<br><br><br><br><br>5 балл<br><br>1 балл |
| 3 | Импортны алыштыру:<br>Россия Федерациясендә җиһазлар (саву аппараты) паспорты нигезендә җитештерелгән өстәмә аппарат;<br><br>Чит ил җитештерүчесенең өстәмә аппараты | 1 - 5 балл<br><br>5 балл<br><br><br>1 балл |

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.spasskiy.tatarstan.ru) һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Р.Р. Закировага йөкләргә.

ТР Спас муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе

В.А. Осокин